КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 февраль г.Казань № 107

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына акчалата түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указының 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына акчалата түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга - Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1037 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга - Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1037 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга - Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 11 декабрь , 1139 нчы.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 26 февраль, 107 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш кerткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына акчалата түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына акчалата бүләкләүне (алга таба - акчалата бүләкләүне, премия лауреатларын) түләү тәртибен һәм шартларын җайга сала.

2. Акчалата бүләкләү премия лауреатларына - гражданнарга һәм премия лауреатларына - социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турында нигезләмәдә билгеләнгән күләмдә түләнә.

3. Акчалата түләү бюджет акчаларын баш бүлүче функцияләрен гамәлгә ашыручы, аңа, бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан (алга таба - вәкаләтле орган) тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.

4. Акчалата түләү шартлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Президенты указы белән премия бирү;

премия бирү турында Татарстан Республикасы Президенты указы басылып чыккан көннән алып 60 көн эчендә, әмма бу елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга акчалата түләү өчен мөрәҗәгать;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләре булмау;

5. Премия лауреатына - социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмага акчалата түләү Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә премия бирү турындагы Указы нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 4 пункты нигезендә

акчалата бүләкләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү турындагы указы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Премия лауреатына - гражданга акчалата бүләкләү әлеге Нигезләмәнең 7 - 13 пунктларында билгеләнгән тәртиптә түләнә.

7. Акчалата бүләкләүне түләү өчен премия лауреаты - гражданин яисә аның вәкиле (алга таба шулай ук - мөрәҗәгать итүче) әлеге Нигезләмәнең 4 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срокта вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

акчалата түләүне түләү турында гариза (алга таба - гариза) вәкаләтле орган билгеләгән форма буенча;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның күчермәсе;

салым түләүченең идентификация номеры турында белешмәләр булган документның күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның күчермәсен;

премия лауреаты вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе, премия лауреаты вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ - премия лауреаты вәкиленең акчалата бүләкләвен түләү өчен мөрәҗәгать иткән очракта.

Әлеге пунктның өченче - алтынчы абзацларында күрсәтелгән документларның күчермәләре аларның тиңдәшлеге таныклыгы өчен төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла йә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныклана.

8. Мөрәҗәгать итүче вәкаләтле органга салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында белешмә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Вәкаләтле орган кергән көнендә гаризаны терки.

10. Вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гариза теркәлгән көннән алып тапшырылган документларны һәм аларда булган белешмәләрне, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, ведомствоара гарызнамәләр нигезендә тикшерә һәм акчалата түләүне түләү турында яисә акчалата түләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында аны кабул иткән көненнән алып эш көннәрендә санала торган ике көн эчендә хәбәр итә.

Акчалата түләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган хәбәрнамәдә тиешле нигезләрне күрсәтә, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны кире кайтара.

11. Акчалата түләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;

әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән акчалата түләүнең түләү шартларына туры килмәве.

12. Акчалата түләү, гаризада күрсәтелгән кредит оешмасында ачылган шәхси счетка акчалар күчерү юлы белән акчалата түләү түләү турында карар кабул ителгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

13. Вәкаләтле орган салым агенты булып тора һәм салым түләүчене исәпләп чыгару, тотып калу һәм премия лауреатларына - гражданнарга акчалата бүләкләү буенча физик затлар керемнәренә салымны Россия Федерациясе бюджет системасына күчерү бурычларын үти.